| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |
|---|---|

**Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе турында» 2015 елның 9 маендагы ПУ-431 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы һәм 2017 елның 28 июнендәге ПУ-553 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) комиссия составыннан А.М. Забурдаевны, А.Т. Насыйровны, А.М. Пахомовны, Р.С. Сафиуллинны чыгарырга;

б) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Данилина Юлия Вячеславовнаны – Аккредитация буенча федераль хезмәтнең Идел буе федераль округы буенча идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Ткачев Вадим Викторовичны – Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Урта Идел территориаль идарәсе җитәкчесен;

Шәйхетдинова Любовь Николаевнаны – Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесен.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 13 апрель
№ ПУ-219